КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 февраль г.Казань № 72

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм контрольдә тоту чараларын үтәүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләр) бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 23 май, 481 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм контрольдә тоту чараларын үтәүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләр) бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм контрольдә тоту чараларын үтәүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләр) бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 23 май, 481 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 февраль, 155 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм контрольдә тоту

чараларын үтәүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләр) бирү тәртибенә, 11 пунктның унтугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Заявка составында кәгазьдә тапшырылган барлык документлар аңлаешлы итеп бастырып чыгарылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр (коммерциягә карамаган оешманың вәкаләтле заты имзасы һәм мөһер (булганда) белән расланган төзәтүләрдән тыш) рөхсәт ителми. Заявканың барлык битләре номерланган булырга тиеш. Гариза тегелгән һәм коммерциягә карамаган оешманың вәкаләтле заты имзасы белән таныкланган һәм гаризаның икенче ягында битләрнең гомуми санын күрсәтеп, мөһер (мөһер булган очракта) белән беркетелгән булырга тиеш.».

2. Бу карар 2024 елның 1 июненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры А.В.Песошин